| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |
|---|---|---|

| ПРИКАЗ | | БОЕРЫК |
|---|---|---|
| 24.12.2021 | Казан шәһәре | № 127 |

Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы, «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 елның 12 ноябрендәге 622 номерлы карарлары нигезендә боерык бирәм:

1. Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә дәүләт хезмәте күрсәтүне турыннан-туры тәэмин итүче җитәкче урынбасар-ларына, структур бүлекчәләрнең җитәкчеләренә әлеге Регламент нигезләмә-ләренә тайпылмыйча таянып эш итәргә.

3. Хокукый эш һәм өлешле төзүне тикшереп тору идарәсенең юридик бүлегенә әлеге боерыкны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. Җыелма анализһәм мәгълүмат технологияләре бүлегенә Регламентны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең түбәндәге боерыкларын гамәлдән чыккан дип танырга:

«Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 17 сентябрендәге 84 номерлы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2018 елның 17 сентябрендәге 84 номерлы боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 7 июнендәге 68 номерлы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2018 елның 17 сентябрендәге 84 номерлы боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 4 октябрендәге 109 номерлы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2018 елның 17 сентябрендәге 84 номерлы боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 8 июнендәге 56 номерлы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2018 елның 17 сентябрендәге 84 номерлы боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 24 июнендәге 54 номерлы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2018 елның 17 сентябрендәге 84 номерлы боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм

капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 15 июлендәге 59 номерлы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2018 елның 17 сентябрендәге 84 номерлы боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 25 октябрендәге 95 номерлы.

6. Әлеге боерык үтәлүен тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе җитәкчесенең беренче урынбасары И.Ф.Сафиуллинны җаваплы итеп билгеләргә.

Җитәкче В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы Дәүләт
төзелеш күзәтчелеге
инспекциясенең 24.12.2021 № 127
боерыгы белән расланды

# Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – дәүләт хезмәте, Регламент).

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып төзүче оешма яисә техник заказчы тора.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе (алга таба – Инспекция) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3.1. Инспекция урнашкан урын (почта адресы): 420111, Казан шәһәре, Большая Красная урамы, 15/9.

Инспекциянең эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән тыш көн саен, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.30 башлап 17.30 кадәр, җомга 8.30 башлап 16.30 кадәр, төшке аш 12.00 башлап 12.45 кадәр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаларны кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбе көннәреннән кала, Инспекциянең эш сәгатьләрендә.

«КАИ» яки «Ирек мәйданы» тукталышына кадәр җәмәгать транспорты белән килү:

10а, 22, 28, 28а, 30, 35, 54, 63, 89; 91, 98 санлы автобуслар;

2, 3, 5, 7 санлы троллейбуслар;

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Белешмә телефоннары:

237-91-87, 237-87-22

1.3.3. Инспекциянең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы:http://gsn.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Инспекция бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә визуаль һәм тестлы мәгълүматларны үз эченә алган, дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Инспекциянең рәсми сайтында (http://gsn.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал);

3) Инспекциягә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша);

4) Инспекциягә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Инспекциянең урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Инспекциянең электрон почтасы адресы турында мәгълүмат Инспекциянең рәсми сайтында, Бердәм порталда «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында җыелма анализ һәм мәгълүмат технологияләре бүлеге тарафыннан урнаштырыла.

Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендларында, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урында һәм Инспекциянең рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчасындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) Инспекциянең рәсми сайтында (https://gsn.tatarstan.ru), Бердәм порталда «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

төзүче оешма – үзенә караган җир кишәрлегендә яки бүтән төрле хокук иясенеке булган җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны, капиталь ремонтлауны, сүтүне гамәлгә ашыручы, шулай ук төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау өчен инженерлык эзләнүләрен башкаруны, проект документларын әзерләүне тәэмин итүче (дәүләт (муниципаль) мөлкәтенең капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән очракларда, килешүләр нигезендә дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), бюджетныкы булмаган дәүләт фондларының идарә органнары яки җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт (муниципаль) заказчысы буларак үзләренең вәкаләтләре тапшырылган йә килешүләр нигезендә, «Төзүче оешма бөлгенлеккә төшкәндә (банкрот булганда)

гражданнарның – өлешле төзелештә катнашучыларның хокукларын яклау буенча гавәми-хокук компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законның $13^3$ статьясы нигезендә төзүче буларак үзләренең функцияләре тапшырылган) физик зат яки юридик зат. Төзүче оешма шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнарда каралган үз функцияләрен техник заказчыга тапшырырга хокуклы;

техник заказчы – төзүче тарафыннан вәкаләт бирелгән һәм инженерлык эзләнүләрен башкару турында, проект документларын әзерләү турында, капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау турында төзүче исеменнән шартнамәләр төзи торган, эшләрнең күрсәтелгән төрләрен башкаруга йөкләмәләр әзерли, капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау буенча инженерлык эзләнүләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерли торган затларга эшләрнең әлеге төрләрен башкару өчен кирәкле материалларны һәм документларны тапшыра, проект документларын раслый, капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыру өчен рөхсәт алуга кирәкле документларны имзалый, законнарда каралган башка функцияләрне (алга таба шулай ук – техник заказчы функцияләре) һөнәри нигездә эш итеп гамәлгә ашыра торган физик зат яисә юридик зат. Техник заказчы функцияләре бары тик Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба – РФ Шәһәр төзелеше кодексы) 47 статьясындагы $2^1$ өлешендә, 48 статьясындагы $4^1$ өлешендә, 52 статьясындагы $2^1$ һәм $2^2$ өлешләрендә, $55^{31}$ статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, тиешенчә җайга салына торган инженерлык эзләнүләре, архитектура-төзелеш проектлау, төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт, капиталь төзелеш объектларын сүтү өлкәсендә үзкөйләнешле оешма әгъзасы тарафыннан гына үтәлергә мөмкин;

вазыйфаи зат – конкрет капиталь төзелеш объектында законнар нигезендә региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен җаваплы булган, Инспекция җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) боерыгы белән билгеләнгән Инспекциянең территориаль органы хезмәткәре;

төркем җитәкчесе – вазыйфаи затлар арасыннан билгеләнгән, Инспекция җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) боерыгы нигезендә билгеләнә торган, оештыру һәм координация өчен җаваплы, шулай ук дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча вазыйфаи затлар эшчәнлегенә җитәкчелекне гамәлгә ашыручы зат;

Инспекция аппаратының контроль бүлеге – дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган, Инспекция аппаратының дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибе үтәлешен тикшереп тору бүлеге;

территориаль органның кабул итү бүлеге – Инспекциянең территориаль органның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган, төзеп бетерелгән объектларны күзәтү бүлеге;

территориаль орган җитәкчесе – Татарстан Республикасы шәһәрләрендә һәм районнарында региональ дәүләт төзелешен күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча

Инспекциянең структур бүлекчәсе җитәкчесе;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып тора торган), «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

«бер тәрәзә» принцибы – дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле мөрәҗәгать белән яки 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать белән бер мәртәбә мөрәҗәгать иткәннән соң гамәлгә ашырыла торган, ә дәүләт хезмәте күрсәтә торган органнар яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар белән хезмәттәшлек итү мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка гына, норматив хокукый актларга һәм хезмәттәшлек итү турында килешүгә туры китереп күпфункцияле үзәк аша гамәлгә ашырыла торган принцип;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы (алга таба – ИАБС) – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы;

техник хата – Инспекция тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата).

Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты).

Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү.sub_4951

2.2. Башкарма хакимият органы исеме.

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау:

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү (алга таба – ярашлылык турында бәяләмә) (Регламентка 1 нче кушымта);

2) Ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар (Регламентка 2 нче кушымта).

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе рәсмиләштерелә һәм турыдан-туры тапшырыла яки мөрәҗәгать итүчегә сайланган ысул буенча җибәрелә:

язма формада – почта адресы буенча;

электрон документ формасында – электрон почта адресына һәм мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталдагы, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

Актыккы тикшерүне төгәлләгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны бирү срогы, мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, – актыккы тикшерү тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан (почта буенча яки электрон адреска, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына) файдаланып җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

1) капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында кәгазь

чыганакта белдерү (алга таба – гариза) (Регламентка 3 нче кушымта):

Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге Регламентның 2.5.1 пункты таләпләренә туры китереп имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла).

2) төзелеш өчен рөхсәт күчермәсе;

3) тулы күләмдә проект документациясе, ә төзелешнең, үзгәртеп коруның аерым этабына рөхсәт бирелгән очракларда, төзелешнең тиешле этабын гамәлгә ашыру өчен кирәкле күләмдә;

4) кызыл сызыклардан чигенү сызыкларын җирлеккә кертү турында документ күчермәсе (кызыл сызыклар булган очракта);

5) эшләр үтәлешен исәпкә алу алып барыла торган гомуми һәм махсус журналлар;

6) капиталь төзелеш объектының проект документациясе РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә экспертиза узарга тиеш булган очракта, проект документациясенә уңай экспертиза бәяләмәсе;

7) шәхесне раслый торган документ;

8) мөрәҗәгать итүче зат исеменнән персональ белешмәләрне эшкәртүгә рөхсәт бирү вәкаләтен дә күрсәтеп, вәкилнең (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эш йөртсә) вәкаләтләрен раслаучы документ;

9) мөрәҗәгать итүченең яисә мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документ (Инспекциягә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта күрсәтелә).

Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, шәхесне таныклый торган документтагы белешмәләр ИАБС системасында исәпкә алу язуын раслаган вакытта тикшерелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Инспекциягә шәхсән мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Инспекциянең рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

1) Инспекциягә шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат тарафыннан) яисә почта аша кәгазьдә яисә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләре нигезендә имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә;

2) Бердәм портал аша;

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада.

Гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза бирелгән көнне Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетта һәм электрон почта

аша гаризаның җибәрелүен раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәү номеры һәм тапшыру датасы күрсәтелгән була.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик багланышларын тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын да расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затларның вәкилләре гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче документларның электрон рәвешләрен яисә 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә мондый документларны төзү һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар тарафыннан электрон имза белән имзаланган электрон формадагы документларны тапшыра.

2.5.1. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәрелгән гариза мөрәҗәгать итүченең гади электрон имзасы белән имзалана.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар (документларның электрон рәвешләре), шул исәптән ышаныч кәгазьләре pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларындагы файллар рәвешендә җибәрелә.

Электрон документларның (электрон документ рәвешләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә уку һәм документ реквизитларын тану мөмкинлеген бирергә тиеш.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма:

Бу категориягә кертелергә мөмкин булган документларны тапшыру таләп

ителми.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза һәм кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге:

1) гаризаның дәүләт хезмәте күрсәтүгә вәкаләтле булмаган дәүләт хакимияте органына тапшырылуы;

2) гариза формасындагы, шул исәптән Бердәм порталда, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның проактив формасындагы кырларны тулылысынча тутырмау;

3) капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корганда региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеге гамәлгә ашырылмаса;

4) эшнең башлануы турында белдерү һәм аңа теркәп тапшырылган документлар РФ Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 5 өлешендә билгеләнгән тәртипне бозып рәсмиләштерелгән булса;

5) эшләр башлану турында белдерү тиешле (вәкаләтле) булмаган зат тарафыннан бирелгән очракта;

6) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар тулысы белән тапшырылмаганда.

7) тапшырылган документларның дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (шәхесне таныклый торган документ, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, – дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта);

8) мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырылган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы;

9) электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы;

10) гаризаның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон формада билгеләнгән таләпләрне бозып тапшырылуы;

11) 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясында билгеләнгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларының үтәлмәве;

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Инспекциянең рәсми сайтында урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту рөхсәт ителми.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корган вакытта РФ Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясындагы 16 өлешендә күрсәтелгән таләпләр

бозылган очракта, һәм мондый бозулар актыкка тикшерүе тәмамланганчы бетерелмәсә;

актыкка тикшерү барышында капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору эшләренең проект документларында каралган тулы күләмдә тәмамланмаганлыгы ачыкланган очракта. Бу очракта региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы төзүче оешма яисә техник заказчы белән килешенеп, вакыйга җитү, атап әйткәндә, капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору эшләре тәмамлану вакыты өлешендә тикшерүләр программасына үзгәрешләр кертә;

капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, кулланылган төзелеш материалларына, башкарылган эшләргә һәм кулланылучы төзелеш материалларына экспертизаларның, тикшерүләрнең, лаборатор һәм башка сынауларның булмавы.

2.8.1. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Инспекциянең рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр.

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып түбәндәгеләр тора:

капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, кулланылган төзелеш материалларына, башкарылган эшләргә һәм кулланылучы төзелеш материалларына экспертизалар, тикшерүләр, лаборатор һәм башка сынаулар.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп.

Төзелешне гамәлгә ашыручы зат башкарылган эшләргә һәм кулланыла торган төзелеш материалларына экспертизалар, тикшеренүләр, лаборатор һәм башка сынаулар үткәрүгә чыгымнарны каплый.

Күрсәтелгән акчалар бюджет керемнәре администраторының Татарстан Республикасы буенча федераль казначылык идарәсенә күчерелә.

Башкарылган эшләргә һәм кулланыла торган төзелеш материалларына экспертизалар, тикшеренүләр, лаборатор һәм башка сынаулар үткәрү чыгымнарын каплау өчен акча күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә билгеләнә.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый

хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да.

Гариза һәм документлар килгән көнне.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада алынган гариза, Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы гаризалар автомат рәвештә теркәлмәгән очракта, билгеләнгән тәртиптә Инспекция тарафыннан алынган көнендә теркәлә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән Инспекция биналарында һәм бүлмәләрендә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

Инспекция территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Инспекция бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру-төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска ярдәмендә дә;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган

мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртә торган этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, бинага һәм бүлмәләргә сукырларны озата йөри торган этне кертү;

хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү;

2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки андый мөмкинлекнең булмавы

Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган Инспекция биналарының җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

2) мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, Инспекциянең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында тулы мәгълүмат булуы;

4) гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;

5) Инспекция бинасын һәм бүлмәләрен инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итүче чаралар һәм җайланмалар белән җиһазлау (бинага уңайлы керү-чыгу һәм бина чикләрендә

хәрәкәт итү);

6) инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;

2) Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;

3) документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать итүчеләргә тапшырганда чиратлар булмавы;

4) Инспекция белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;

Мөрәҗәгать итүчеләр өчен Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуын һәм сыйфатын бәяләү мөмкинлеге тәэмин ителә.

Мөрәҗәгать итүченең Инспекция белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза белән документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең белгеч белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәргән очракта, турыдан-туры бәйләнеш таләп ителми.

Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Инспекциядә, Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алынырга мөмкин.

Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр.

Мөрәҗәгать итүче Инспекциягә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткән очракта, консультация бирелергә мөмкин. Дәүләт хезмәте электрон формада, шул исәптән Бердәм порталдан, Татарстан

Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып та күрсәтелә.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

3) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы ярдәмендә Инспекция, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон имза белән таныкланган электрон документ формасында бирелә, әгәр бу хакта Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән гаризада күрсәтелгән булса.

Гаризаны җибәргән вакытта, мөрәҗәгать итүченең шәхесе исәпкә алу язуын активлаштырганда билгеләнгән булу шарты белән, гади электрон имза кулланыла.

Гаризаны электрон рәвештә формалаштырганда мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә: гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны күчереп алу һәм саклау мөмкинлеге:

гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән электрон формага ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон формага элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

ИАБС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, ИАБС

системасында урнаштырылган һәм Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон гариза формасы кырларын тутыру;

элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында элек бирелгән гаризаларын карый алу мөмкинлеге.

Гаризаны җибәргән вакытта, мөрәҗәгать итүченең шәхесе исәпкә алу язуын активлаштырганда билгеләнгән булу шарты белән, гади электрон имза кулланыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша гамәлгә ашырыла.

Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша кабул итүгә язылу өчен система сораган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән: фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта); телефон номеры; электрон почта адресы (ихтыярга карап); теләнгән дата һәм кабул итү вакыты.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә.

Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Кабул итүгә алдан язылган вакытта билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру

үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) гаризаны һәм документларны карау һәм кабул итү яки кабул итүдән баш тарту;

3) актыккы тикшерүне әзерләү һәм үткәрү;

4) ярашлылык турында бәяләмә яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар бирү (җибәрү);

5) техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша, электрон почта һәм (яисә) хат аша Инспекциягә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итә.

Инспекция аппаратының контроль бүлеге (территориаль органның кабул итү бүлеге) белгече шәхсән, телефон, электрон почта һәм (яки) хат белән, мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча да, һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә, мөрәҗәгать итүчегә Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация алырга хокуклы.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультация, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә, мөрәҗәгать итүчегә Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү.

3.2.1. Гаризаны һәм документларны карау һәм кабул итү яки кабул итүдән баш тарту.

Мөрәҗәгать итүчедән шәхсән яисә вәкаләтле зат аша, шул исәптән Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша, гаризаның һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында

билгеләнгән документларның Инспекциягә алынуы административ гамәлне башлап җибәрү нигезе булып тора.

Документларны электрон рәвештә тапшыру өчен аларның 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон рәвештә имзаланган булуы мәҗбүри шарт булып тора.

3.2.2. Инспекциягә алына торган корреспонденцияне теркәү һәм «Татарстан Республикасы Электрон хөкүмәте» бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында документ әйләнешен алып бару өчен җаваплы булган Инспекциянең вазыйфаи заты (алга таба – БВЭДӘС администраторы), документар формада документлар алынган очракта, Инспекциягә алынган гаризаны кушымталары булган документлары белән бергә терки һәм аны Инспекция җитәкчесе исеменә җибәрә, документлар электрон формада алынган очракта, Бердәм порталга, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталына (мөрәҗәгать итүче тарафыннан документларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән таныкланган электрон үрнәкләре тапшырылган очракта) мөрәҗәгать итү юлы белән, электрон имзаның гамәлдә булу шартлары үтәлешен тикшерә, кушымтадагы документлары белән Инспекциягә алынган гаризаны терки һәм Инспекция җитәкчесе исеменә җибәрә.

Инспекция җитәкчесенең резолюциясе алынганнан соң, кушып тапшырыла торган документлары белән бергә эшләр башлануы турындагы хәбәр документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелә.

Документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

1) документлар документар формада алынган очракта:

документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, вазыйфаи затлар тикшерүләр программасын төзи һәм раслыйлар, ул мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә.

Тикшерүләр программасында тикшерүләр программасы нигезендә контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү өчен нигез булып торган вакыйгалар күрсәтелә, аерым алганда:

а) тикшерелергә тиешле, башкарылган эшләрне тәмамлау;

б) капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны тәмамлау.

әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булган очракта, гариза һәм документларны документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләр эчтәлеген язмача аңлатып кире кайтара (Регламентка 7 нче кушымта).

2) документлар электрон формада килгән очракта:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формада теркәлгән документларны һәм документларның электрон рәвешләрен өйрәнә;

мөрәҗәгать итүченең, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7

пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, вазыйфаи затлар тикшерүләр программасын төзи һәм раслыйлар, ул мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә.

Тикшерүләр программасында тикшерүләр программасы нигезендә контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү өчен нигез булып торган вакыйгалар күрсәтелә, аерым алганда:

а) тикшерелергә тиешле, башкарылган эшләрне тәмамлау;

б) капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны тәмамлау.

әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булган очракта, гариза һәм документларны документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләр эчтәлеген язмача аңлатып кире кайтара (Регламентка 7 нче кушымта).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, гариза һәм документлар электрон формада ял (бәйрәм) көнендә алынган очраклардан тыш, гариза һәм документлар алынган көннән соң унөч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Инспекция җитәкчесенә теркәлгән документлары белән тапшырылган гариза, расланган һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән тикшерүләр программасы; мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Актыккы тикшерүне әзерләү һәм үткәрү.

3.3.3.1. Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору эшләре тәмамланганнан соң тикшерүләр программасында күрсәтелгән вакыйга башланган очракта төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) актыккы тикшерүне үткәрү турында карар әзерли һәм тикшерү турында белешмәләрне Контроль (күзәтчелек) чараларның бердәм реестрына (алга таба – ККЧБР) кертә һәм карарның күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар тикшерү уздыруга кадәр егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәләре: әзерләнгән һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән актыккы тикшерүне үткәрү турында карар.

3.3.3.2. Тикшерү үткәрү турындагы карарда күрсәтелгән тикшерү датасы җиткән очракта, вазыйфаи затлар тарафыннан актыккы тикшерү үткәрелә, аның нәтиҗәләре буенча башкарылган эшләр бәяләнә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура ун эш көненнән артмаган чорда гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: үткәрелгән актыккы тикшерү.

3.3.4. Ярашлылык турында бәяләмә яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар бирү (җибәрү).

3.3.4.1. Төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат), әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар һәм ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баә тарту турында карар раслау турындагы күрсәтмә проектын әзерли, аларны территориаль орган җитәкчесе белән килештерә, имзалау өчен Инспекция

җитәкчесенә (җитәкче урынбасарына), ә аннары, әлеге Регламентның 3.3.4.6 пунктында каралган гамәлләрне башкару өчен, Инспекция аппаратының контроль бүлегенә җибәрә.

Төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) ярашлылык турында бәяләмә бирү турындагы гаризаны карап тикшерә һәм, әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда формалаштырылган эшне (алга таба – формалаштырылган эш) территориаль органның кабул итү бүлегенә яки, андый булмаса, территориаль орган җитәкчесенә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәләре: территориаль органның кабул итү бүлегенә (территориаль орган җитәкчесенә) җибәрелгән, формалаштырылган эш яки Инспекция аппаратының контроль бүлегенә җибәрелгән, ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар һәм ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар раслау турында күрсәтмә проекты.

3.3.4.2. Формалаштырылган эш алынган очракта, территориаль органның кабул итү бүлеге (территориаль орган җитәкчесе) аны составы һәм комплектлылыгы буенча тикшерә.

Территориаль органның кабул итү бүлеге (территориаль орган җитәкчесе) тарафыннан формалаштырылган эшне тикшергәндә ачыкланган кисәтүләр булса, төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) белән берлектә, аларны бетерүне тәэмин итә.

Кисәтүләр булмаган очракта яисә алар бетерелгәннән соң территориаль органның кабул итү бүлеге (территориаль орган җитәкчесе) формалаштырылган эшне Инспекция аппаратының контроль бүлегенә тикшерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура беткәч бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Инспекция аппаратының контроль бүлегенә җибәрелгән формалаштырылган эш.

3.3.4.3. Формалаштырылган эшне алганнан соң Инспекция аппаратының контроль бүлеге аны законнардагы таләпләргә туры килүе буенча, шул исәптән дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда вазыйфаи затлар тарафыннан законнардагы таләпләрне үтәү предметына тикшереп чыга.

Төзеп бетерелгән капиталь төзелеш объектына тикшерү уздырганда вазыйфаи затлар тарафыннан шәһәр төзү законнарындагы таләпләр үтәлүен тикшерү максатларында Инспекция аппаратының контроль бүлеге, зарурлык булса, капиталь төзелеш объектына чыга.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча Инспекция аппаратының контроль бүлеге ачыкланган хокук бозуларны күрсәтеп яки җитешсезлекләрнең булмавы турында хисап әзерли һәм аны Инспекция җитәкчесенә (җитәкче урынбасарына) җибәрә. Әлеге хисап нигезендә ярашлылык турында бәяләмә бирү яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ярашлылык турында бәяләмә бирү яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында кабул ителгән карар.

3.3.4.4. Ярашлылык турында бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар формалаштыру.

Ярашлылык турында бәяләмә бирү турында карар кабул ителгән очракта, территориаль органның кабул итү бүлеге, төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) белән берлектә:

ярашлылык турында бәяләмә һәм ярашлылык турында бәяләмә раслау турында күрсәтмә проектын әзерли (әлеге Регламентка 4 нче кушымта);

ярашлылык турында бәяләмә раслау турында күрсәтмәне территориаль орган җитәкчесе, Инспекция аппаратының контроль бүлеге җитәкчесе белән килештерә;

ярашлылык турында бәяләмә бланкын тутыра;

ярашлылык турында бәяләмәне һәм ярашлылык турында бәяләмә раслау турындагы күрсәтмәне төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерүдә катнашкан барлык җаваплы вазыйфаи затлардан, территориаль орган җитәкчесеннән, Инспекция җитәкчесеннән (җитәкче урынбасарыннан) имзалаттыра һәм аларны Инспекция аппаратының контроль бүлегенә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Регламентның 3.3.4.3 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Инспекция аппаратының контроль бүлегенә тапшырылган, әзерләнгән ярашлылык турында бәяләмә, ярашлылык турында бәяләмә раслау турында күрсәтмә.

3.3.4.5. Ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, территориаль орган җитәкчесе тиешле карарны территориаль органның кабул итү бүлегенә яисә төркем җитәкчесенә (вазыйфаи затка) тапшыра.

Территориаль органның кабул итү бүлеге, төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) белән берлектә, ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар һәм ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар раслау хакында күрсәтмә проектын әзерлиләр, аларны территориаль орган җитәкчесе, Инспекция аппаратының контроль бүлеге җитәкчесе белән килештерәләр, Инспекция җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан имзалаттыралар һәм Инспекция аппаратының контроль бүлегенә тапшыралар.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Регламентның 3.3.4.3 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Инспекция аппаратының контроль бүлегенә тапшырылган ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар һәм ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар раслау турында күрсәтмә.

3.3.4.6. Инспекция аппаратының контроль бүлеге:

ярашлылык турында бәяләмә раслау турында күрсәтмәне яки ярашлылык

турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карарны раслау турындагы күрсәтмәне терки;

ярашлылык турында бәяләмә бланкына Инспекциянең герблы мөһере һәм клише эзләрен төшерә;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) ярашлылык турында бәяләмәне яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы карарны тапшыра, шул ук вакытта мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) шәхесен билгели, шул исәптән шәхесне таныклый торган документны тикшерә;

мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен (ышанычнамә) тикшерә.

Ярашлылык турында бәяләмәнең яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы карарның икенче нөсхәсе Инспекция аппаратының контроль бүлегендә кала;

мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) килмәсә, гариза кәгазьдә җибәрелгән икән, ярашлылык турында бәяләмә бирү турында карар яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар кабул итү очрагында, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында почта буенча хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, Регламентның 3.3.4.4, 3.3.4.5 пунктларында һәм 3.3.4.1 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән процедуралар беткәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) ярашлылык турында бәяләмә яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар бирү (җибәрү).

3.4. Техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

Ярашлылык турындагы бәяләмәдә яисә ярашлылык турында шундый бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы карар техник хата (язу хатасы, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата) ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша Инспекциягә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта);

техник хатасы (язу хатасы, басма хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган ярашлылык турында бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар;

техник хатасы (язу хатасы, басма хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Ярашлылык турындагы бәяләмәдә яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы карарда күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны (язу хатасын, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турындагы гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән яисә мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле вәкиле аша кәгазьдә яисә көчәйтелгән квалификацияле

электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен һәм Бердәм порталны, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталын да кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша тапшырыла.

Документлар белән тәэмин итү һәм контроль бүлеге техник хатаны (язу хатасын, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән гаризаны терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

Территориаль органның кабул итү бүлеге яисә, андый булмаса, төркем җитәкчесе (вазыйфаи зат) документларны карый һәм, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларга төзәтмәләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.3.4.4 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны Инспекция аппаратының контроль бүлегенә җибәрә.

Инспекция аппаратының контроль бүлеге мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы (язу хатасы, басма хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документ оригиналын алып, үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) имзалатып тапшыра яисә мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) адресына дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында почта буенча хат җибәрә.

Техник хатаны төзәтү турындагы гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон рәвештә бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны электрон рәвештә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата (язу хатасы, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата) ачыкланганнан соң яки мөрәҗәгать итүчедән (мөрәҗәгать итүче вәкиленнән) техник хата (язу хатасы, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата) җибәрелүе турында гариза алынганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) үзгәртеп рәсмиләштерелгән ярашлылык турында бәяләмә яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар бирү (җибәрү).

3.5. Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата

шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

- эш башкаруның алып барылышы, шул исәптән документларны кабул итү вакытларының һәм тәртибенең үтәлеше;
- документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;
- дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытлары, тәртибе үтәлүе.

Тикшерүләр уздыру ешлыгы даими характерда.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы тикшерү Инспекция аппаратының контроль бүлеге һәм Инспекция җитәкчесе урынбасары җитәкчелегендә башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольлекне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеге Инспекциянең структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрдә, вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тикшереп тору Инспекция җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Инспекция эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Инспекция, Инспекциянең вазыйфаи заты, дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Инспекциягә шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә Инспекция җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы

бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Инспекциянең, Инспекция вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның дәүләт хезмәткәренең, җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Шикаять мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында, КФҮ аша кабул ителергә мөмкин, почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Инспекциянең рәсми сайтын (http://gsn.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелә ала.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне

эчендә. Инспекциянең, Инспекция вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы икенче көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7.1. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Инспекция тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7.2. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

(Рәвеше)

______________________________________________________________

(Дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының исеме)

РАСЛАНДЫ 20___
елның «____» _______________
№ ___ боерык (күрсәтмә) белән

Эш номеры___________________
Нөсхә №_________________

Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында БӘЯЛӘМӘ

________________________________ «_______»______________ 20____ел.

(төзү урыны)

Әлеге БӘЯЛӘМӘ бирелде

______________________________________________________________________

(төзүче яисә техник заказчының исеме, төп дәүләт теркәү номеры, шәхси тәңгәллек саны, урнашу урыны – юридик затлар өчен; фамилиясе, исеме, атасының исеме [1], яшәү урыны адресы, шәхси эшкуарларның төп дәүләт теркәү номеры, шәхси тәңгәллек саны – шәхси эшкуарлар өчен; фамилиясе, исеме, атасының исеме [1], паспорт белешмәләре, яшәү урыны адресы – физик затлар өчен)

һәм шуны раслый: капиталь төзелеш объекты

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

(төзелеш, үзгәртеп кору этабына рөхсәт бирелгән булса, капиталь төзелеш объектының исеме, кыска проект характеристикалары, төзелеш, үзгәртеп кору этапының тасвирламасы)

урнашкан адресы:

______________________________________________________________________

(капиталь төзелеш объектының почта яисә төзелә торган адресы)

Капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт

______________________________________________________________________

(бирелгән номеры һәм датасы, аны биргән орган яки оешма, гамәлдә булу срогы)

Проект документациясенә уңай экспертиза бәяләмәсе

______________________________________________________________________

(бәяләмә номеры һәм аны бирү датасы, аны раслаган орган яки оешма[2]; проектның баш инженеры бәяләмәсе[3])

Төзүне, үзгәртеп коруны башлау ____________________________________________

(эшләрне башлау датасы)

төзүне, үзгәртеп коруны тәмамлау _________________________________________

(эшләрне тәмамлау датасы)

Таләпләргә ТУРЫ КИЛӘ

______________________________________________________________________

(проект документлары бүлекләренең исемнәре һәм шифрлары)

Капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге классы[4]

______________________________________________________________________

Әлеге БӘЯЛӘМӘНЕ бирү нигезләре:

______________________________________________________________________

(төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерү акты номеры, датасы)

_________________________ ___________________/__________________________/

(вазыйфа) (имза) (тулы имза, дата) [5]

Бәяләмә нөсхәсе алынды:

______________________________________________________________________

(төзүче оешманың яисә техник заказчының вәкиле тарафыннан вәкиллек турында документ реквизитларын күрсәтеп тутырыла)

__________________________ ___________________/_________________________/

(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

---

[1] Булган очракта күрсәтелә.

[2] Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9, 3.10 өлешләре нигезендә эксперт ярдәме барышында бирелгән экспертиза бәяләмәләре дә күрсәтелә.

[3] Төзүче оешма яисә техник заказчы тарафыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлеше нигезендә проект документларына кертелгән үзгәрешләр расланган очракта.

[4] Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнар нигезендә билгеләнә торган энергетика нәтиҗәлелеге классын бирү мәҗбүри булган капиталь төзелеш объектларына карата күрсәтелә.

[5] Бәяләмә объект төзелеп беткән (үзгәртеп корылган) объектны тикшерүдә (тикшерүләрдә) катнашкан дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының вазыйфаи затлары тарафыннан имзалана.

Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

(Рәвеше)

________________________________________________________________
(Дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының исеме)

РАСЛАНДЫ 20___ елның
«____» _______________ № ___ боерык
(күрсәтмә) белән

Эш номеры_____________
Нөсхә №________________

Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында
КАРАР

______________________________ «______»_______________20___ ел
(төзү урыны)

Әлеге КАРАР бирелде
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
(төзүче яисә техник заказчының исеме, төп дәүләт теркәү номеры, шәхси тәңгәллек саны, урнашу урыны – юридик затлар өчен; фамилиясе, исеме, атасының исеме[1], яшәү урыны адресы, шәхси эшкуарларның төп дәүләт теркәү номеры, шәхси тәңгәллек саны – шәхси эшкуарлар өчен; фамилиясе, исеме, атасының исеме[1], паспорт белешмәләре, яшәү урыны адресы – физик затлар өчен)

төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яки) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында БӘЯЛӘМӘ бирүдән баш тарту хакында

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

(төзелеш, үзгәртеп кору этабына рөхсәт бирелгән булса, капиталь төзелеш объектының исеме, кыска проект характеристикалары, төзелеш, үзгәртеп кору этапының тасвирламасы)

урнашкан адресы:

________________________________________________________________________

(капиталь төзелеш объектының почта яисә төзелә торган адресы)

Капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт

________________________________________________________________________

(бирелгән номеры һәм датасы, аны биргән орган яки оешма, гамәлдә булу срогы)

Проект документациясенә уңай экспертиза бәяләмәсе

________________________________________________________________________

(бәяләмә номеры һәм аны бирү датасы, аны раслаган орган яки оешма [2]; проектның баш инженеры бәяләмәсе[3])

Төзелеш, үзгәртеп кору эшләрен башлау ______________________________________

(эшләрне башлау датасы)

төзүне, үзгәртеп коруны тәмамлау ___________________________________________

(эшләрне тәмамлау датасы)

Әлеге КАРАР төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерү нәтиҗәләре нигезендә кабул ителде

________________________________________________________________________,

(төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерү акты номеры, датасы)

анда билгеләнгәнчә:

________________________________________________________________________

(таләпләре бозылган һәм төзелеше тәмамланган капиталь төзелеш объектын тикшерү тәмамланган көнгә бетерелмәгән проект документларының исеме һәм реквизитлары)

____________________________
____________________________ _________________/____________________________/

(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

Бәяләмә нөсхәсе алынды:

________________________________________________________________________

(төзүче оешманың яисә техник заказчының вәкиле тарафыннан вәкиллек турында документ реквизитларын күрсәтеп тутырыла)

_______________________________
_______________________________ ___________________/_______________________________/
(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

---

[1] Булган очракта күрсәтелә.
[2] Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9, 3.10 өлешләре нигезендә эксперт ярдәме барышында бирелгән экспертиза бәяләмәләре дә күрсәтелә.
[3] Төзүче оешма яисә техник заказчы тарафыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлеше нигезендә проект документларына кертелгән үзгәрешләр расланган очракта.

Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

(Рәвеше)

Капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны башлау турында
№ _____ белдерү

________________________ «____» ____________ 20__ел
(төзү урыны)

1. Төзүче (техник заказ бирүче)

__________________________________________________________________________

(шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме[1], яшәгән урыны буенча адресы, төп дәүләт теркәү номеры, шәхси тәңгәллек саны,

__________________________________________________________________

юридик зат атамасы, төп дәүләт теркәү номеры, шәхси тәңгәллек саны, урнашу урыны,

__________________________________________________________________

телефон/факс, әгъзасы булып торган үзкөйләнешле оешма атамасы, төп дәүләт теркәү номеры, шәхси тәңгәллек саны[2] – шәхси эшкуарлар һәм юридик затлар өчен;

__________________________________________________________________

фамилиясе, исеме, атасының исеме[1], паспорт белешмәләре, яшәгән адресы, телефон/факс – шәхси эшкуар булып тормаган физик затлар өчен)

2. Капиталь төзелеш объекты

__________________________________________________________________________

(капиталь төзелеш объектының атамасы

__________________________________________________________________

төзелешкә рөхсәт нигезендә, кыскача проект характеристикалары,

__________________________________________________________________

төзү, үзгәртеп кору этабының тасвирламасы, әгәр рөхсәт төзелеш, үзгәртеп корылыш этабына бирелгән булса)

3. Капиталь төзелеш объектының адресы (урнашкан урыны)

__________________________________________________________________________

(капиталь төзелеш объектының почта яисә төзелә торган адресы)

4. Капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт

___________________________________________________________________________
(бирелгән номеры һәм датасы, аны биргән орган яки оешма, гамәлдә булу срогы)

5. Проект документациясенә уңай экспертиза бәяләмәсе

___________________________________________________________________________
(номеры һәм бирелгән көне,раслаган орган яки оешма)

6. Төзүне, үзгәртеп коруны башлау

___________________________________________________________________________
(эшләрне башлау датасы)

7. Төзүне, үзгәртеп коруны тәмамлау

___________________________________________________________________________
(эшләрне тәмамлау датасы)

8. Төзүче оешма яисә техник заказчы тарафыннан килешү нигезендә җәлеп ителгән, төзелешне гамәлгә ашыра торган шәхси эшкуарлар, юридик затлар исемлеге, әгъза булып торган үзкөйләнешле оешмаларның атамасын һәм реквизитларын күрсәтеп

___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

9. Кушымталар:

___________________________________________________________________________
(белдерүгә теркәлә торган документлар

___________________________________________________________________________
Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 5 өлеше нигезендә)

_________________________________
_________________________________
_________________________________
(төзүче оешма яки техник заказчы вәкиленең ФИА)

_________________________
(имза)

---

[1] Булган очракта күрсәтелә.
[2] Инженерлык эзләнүләре, архитектура-төзелеш проектлары, төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонт һәм капиталь төзелеш объектларын сүтү өлкәсендә үзкөйләнешле оешмаларда әгъза булып торуны таләп ителми торган очраклардан тыш.

Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

(Рәвеше)

РАСПОРЯЖЕНИЕ КҮРСӘТМӘ

__________________ Казан шәһәре № __________________

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча гомуми таләпләрне раслау, 2021 елның 30 июнендәге 1087 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 1 декабрендәге 2161 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 елның 12 ноябрендәге 622 номерлы карары, Инспекциянең _______________________ № ____ боерыгы белән расланган Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты һәм актыкка тикшерү уздыру турында _________________ № ______ акт нигезендә, ______________________ адресы буенча урнашкан, төзелгән (үзгәртеп корылган) капиталь төзелеш объектының ________________________ Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә РАСЛЫЙМ.

Җитәкче урынбасары ______________________

Искәрмә: боерык Инспекция аппаратының контроль бүлеге җитәкчесе, территориаль орган җитәкчесе тарафыннан килештерелә.

Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

(Рәвеше)

РАСПОРЯЖЕНИЕ

КҮРСӘТМӘ

__________________ Казан шәһәре № __________________

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча гомуми таләпләрне раслау, 2021 елның 30 июнендәге 1087 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 1 декабрендәге 2161 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 елның 12 ноябрендәге 622 номерлы карары, Инспекциянең _______________________ № ____ боерыгы белән расланган Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты һәм актыкка тикшерү уздыру турында ________________ № ______ акт нигезендә, аның нигезендә түбәндәгеләр билгеләнде:

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

җитешсезлекләр

________________________ адресы буенча урнашкан, төзелгән (үзгәртеп корылган) капиталь төзелеш объектының ____________________________ Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе

таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар РАСЛЫЙМ.

Җитәкче урынбасары ___________________________

Искәрмә: боерык Инспекция аппаратының контроль бүлеге җитәкчесе, территориаль орган җитәкчесе тарафыннан килештерелә.

Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе җитәкчесенә

________________________________________

Техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм

______________________________________________________________________

(күрсәтелгән хезмәтнең атамасы)

Язылган:____________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: _____________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яисә арифметик хатаны) төзәтүегез һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегез турында сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яисә арифметик хаталарны) төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта мондый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

e-mail:________________________________ адресына электрон документ рәвешендә;

кәгазь документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша түбәндәге адрес буенча: ___________________________җибәрүегез турында сорыйм.

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда

да, алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне дә кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, файдалана алмаслык итүгә, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләргә) үз ризалыгымны, минем тарафтан вәкил булган затның риза булуы хакында раслыйм.

Раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм минем тарафтан вәкил булган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

_________________________ ___________________(______________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.)[1]

[1] Ата исеме булган очракта күрсәтелә

Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны
кабул итүдән баш тарту турында
КАРАР

________________________________________ мөрәҗәгать итүенә бәйле рәвештә
(Мөрәҗәгать итүче – физик затның ФИА[1], юридик зат атамасы)
__.__.____ ел, № ___ гариза
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
түбәндәгеләр нигезендә:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гаризаны һәм кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде, чөнки:

1.
2.

Вазыйфаи зат (ФИА) ___________________________________________________
(органның имзалаучы вазыйфаи затының имзасы)

Башкаручы (ФИА)
_______________________________
(башкаручының элемтә белешмәләре)

Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Капиталь төзелеш объектын төзи, үзгәртеп кора башлау турында хәбәр кабул итү, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары һәм (яисә) мәгълүмат моделе таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аны күрсәтүне тикшерүдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе

| | | |
|---|---|---|
| Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе җитәкчесе | (843) 237-91-87 | Vasiliy.Kudryashov@tatar.ru |
| Җитәкченең беренче урынбасары | (843) 237-91-87 | Ilfart.Safiullin@tatar.ru |
| Инспекция җитәкчесе урынбасары | (843) 518-48-99 | Rafail.Gayanov@tatar.ru |
| Инспекция җитәкчесе урынбасары | (843) 237-91-87 | Linar.Fatyhov@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | электрон адресы |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юллар хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе | (843) 264-77-16 | Ildar.Sibgatullin@tatar.ru |
| Юллар һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын гамәлгә ашыру бүлеге җитәкчесе | (843) 264-77-24 | Yuriy.Azin@tatar.ru |